# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

унынчы утырыш

**КАРАРЫ**

19 май 2021 ел **№ 55** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы контроль-хисап палатасының 2020 елдагы эшчәнлегенә хисап турында

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Уставына, 2016 елның 17 февралендә кабул ителгән 29 санлы карары белән расланган Теләче муниципаль районы контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәгә (2013 елның 04 февралендәге 145 санлы карар редакциясендә) туры китереп һәм контроль-хисап палатасы рәисе С. И. Фәрхетдиновның контроль-хисап палатасының 2020 елдагы эшчәнлеге турындагы хисабы турында фикер алышканнан соң, Теләче муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Теләче муниципаль районы контроль-хисап палатасының 2020 елдагы эшчәнлегенә хисапны исәпкә алырга.

2. Теләче муниципаль районы контроль-хисап палатасының 2020 елдагы эшчәнлеге турындагы хисапны кушымтада тәкъдим ителгән формада һәм эчтәлектә расларга.

3. Теләче муниципаль районы контроль-хисап палатасына 2021 елда йөкләргә:

3. 1. бюджет проектлары һәм район һәм җирлекләр бюджеты үтәлү буенча хисапларга экспертиза уздырып, нәтиҗә чыгару буенча эшне дәвам итәргә;

3. 2. бюджетның барлык статьялары буенча, җирле үзидарә органнарын тотуга булган чыгымнарны да кертеп, бюджетта бүленгән акчаларның законлы һәм нәтиҗәле сарыф ителүенә контроль урнаштырырга;

3. 3. тышкы финанс контроле сферасында үзара ярдәмләшү һәм хезмәттәшлек итү буенча авыл җирлекләре белән килешүләр нигезендә ревизия комиссиясе белән берлектә бюджет проектлары һәм район һәм җирлекләр бюджеты үтәлү турында хисапларга экспертиза уздырып, нәтиҗәләр чыгарырга;

3. 4. муниципаль хокукый актлар проектларының Теләче муниципаль районының чыгымлы йөкләмәләренә, шулай ук муниципаль программаларга кагылышлы өлешенә (финанс-икътисади дәлилләрнең нигезлелеген дә кертеп) финанс-икътисади экспертиза уздырырга;

3. 5. кулланышта булмаган яки (һәм) муниципаль милекнең хуҗалык әйләнешенә кертелмәгән объектларына ревизия уздыруны, аларны тотуга файдасыз чыгымнарны киметүгә һәм юл куймауга юнәлтелгән чаралар күрүне тәэмин итәргә (ярты елга 1 тапкыр).

4. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына һәм муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә:

4. 1. Бюджет акчаларының максатсыз файдалануына юл куймау буенча чаралар күрергә, аларның тулысынча нәтиҗәле файдалануын тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Советының бюджет мәсьәләләре һәм салым салу комитетына йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов